Хәзерге вакытта әдәбият фәнендә мемуар язмаларга игътибар артты. Җәмгыятебездәге үзгәрешләрнең иң зур һәм һәркем үзендә тоя торган нәтиҗәсе фикер йөртүдә, матбугатта ихлас карашларыңны белдерүдә, үткәннәрдәге вакыйгаларны булганынча бәян итүдә чикләүнең йомшаруында күренде. Иҗади шәхесләр дә мондый мөмкинлек булуы турында күп еллар буена хыялланып яшәделәр. Әлеге вәзгыять кешеләрнең хөкем йөртүләренә, фикерләү юнәлешләренә дә нык йогынты ясады, ягъни иҗтимагый тормыштагы мохит шәхеснең эчке дөньясына, шуның нәтиҗәсендә хәтта психологиясенә дә җитди үзгәрешләр алып килде. Шуларга өстәп, милли үзаңның аерым кешеләрдә генә түгел, башлыча, үзен күпчелектә сиздерүе дә документальлеккә ихтыяҗның гомуми төс алуын тәэмин итте. Боларның бөтенесе татар милләтенең дә бай, ләкин бик аз өйрәнелгән рухи мирасына карата булган кызыксынуын арттырды, фәннең милли аспектларының, мәдәниятенең, әдәбиятының һәм рухи-этик традицияләренең төрле катламнарын өйрәнүнең, аларны халыкка кайтаруның зарурлыгын алгы планга чыгарды.

Теге яки бу ихтыяҗ аңа ирешүнең гамәли юлларын эзли башлауны таләп итә, бер үк вакытта аны нәзари нигезләүнең дә янәшә

барырга тиешлеген дә көн тәртибенә куя. Л.Я.Гинзбург хезмәтләрендә боларның кайбер аспектлары күтәрелү очраклы түгел иде. Ул анда, аерым алганда, документаль әдәбият һәм мемуарларның да сәнгатьчә эшләнеш ягыннан әдәби прозага хас сыйфатлардан мәхрүм булмаганлыгын искәртә. Чөнки аларда да характерлар бөтенләе белән тормыштан гына күчереп утыртылмый, бәлки автор карашына һәм бәяләвенә, аның сәнгатьлелеккә ирешү осталыгына бәрабәр дәрәҗәдә индивидуаль образлылыкка ирешеп сурәтләнә. Аның карашынча, «мемуарная литература не пересаживает готовый характер, но, как всякая литература, она его строит» [1: 59]. Болай эшләү тормыштагы геройны үзгәртүгә китермиме дигән сорау тууы да табигый. Юк, китерми, дияргә кирәк, чөнки күзәтүче, тормыштагы геройны башка чыганаклар ярдәмендә дә өйрәнү сәбәпле, сурәтләү объектының индивидуаль якларын шактый төгәл билгели, аларның даимиләрен очраклы күренеп алганнарыннан аеруга ирешә. Әйе, тормышчан герой әсәрдә булганынча сурәтләнсә дә, аның тасвирлаганда автор Л.Гинзбург әйткән «образны төзү материалын» үзеннән дә өсти , әмма ул аның чынбарлыктагы сыйфатларына зыян китермәскә тиеш. Әлеге галимнең карашлары автор белән герой мөнәсәбәтләрен ачыклауга, ул әйткән «шәхестәге тарихны» сәнгатьчә сурәтләү алымнарын сайлау мәсьәләләренә дә кагыла.

С.Антоненко мемуар язмаларда, аерым алганда, хатларда автор шәхесе, стиле чагылуның мөһимлегенә игътибар итә [2: 40]. XX гасыр башына кадәр татар матур әдәбиятында нигездә эпистоляр жанр буларак яшәгән хат, үзенең жанр хасиятләрен үзгәртеп, әдәби тәнкыйть функцияләрен дә үти башлый. «Хат – әдәби тәнкыйть жанры. Ул әдәби тәнкыйтьнең аерым шәхескә атап язылып, әдәби әсәр, язучы иҗаты, әдәби хәрәкәт турында хөкем йөртеп, бәя элементлары да алган эпистоляр жанр» [3: 203]. Әлеге караш татар әдәби тәнкыйть тарихын һәм аның поэтикасын өйрәнүгә зур өлеш керткән Р.Харрасова [4: 22], Ә Закирҗановлар[5: 266-267] тарафыннан да раслана. Бу чыннан да шулай, чөнки талантлы язучының шәхси хатлары да (бигрәк тә иҗатташ коллегаларына адресланганнары) еш кына әдәби кыйммәткә ия була. Ник дигәндә, аларда гадәттә иҗатка мөнәсәбәтле фикерләрнең асылташ кебек ялтыраганнары да булуы сирәк күренеш түгел.

Әйтик, Г.Тукайның замандашы С.Рәмиевкә 1911 елның 4 мартында язган хатында әйткән сүзләре иҗатташын гына түгел, аның үзен дә бәяләү сүзләре булып аңлашыла: «Мин бит синең шикелле, саф, коеп куйган поэт кына түгел, мин дипломат, политик, общественный деятель дә бит. Минем күз күпне күрә, колак күпне ишетә» [6: 105]. Күрәбез, Г.Тукай бу очракта да иҗатчы булып кала, хат аның өчен шәхси асылының ачылу мәйданы. Татар әдәби тәнкыйтендә хат жанрын нигезләүчеләрнең берсе буларак, Габдулла Тукай хатларын җентекле тикшергән галим Т.Гыйлаҗев болай дип яза: «Г.Тукайның Ф.Әмирханга, С.Сүнчәләйгә, Ә Урманчиевка язган хатлары әдәби тәнкыйть билгеләрен гәүдәләндерә. Шагыйрь хатларында да, принципиаль, шәхси мөнәсәбәтләрдән өстен, туры сүзле, вакыты белән усал булып кала. Г Тукай язмалары шулай ук заман әдәбиятының күп мәсьәләләрен күтәрүе, яңа әсәрләр турында тәнкыйди фикерләр язуы белән аерылып тора» [7: 11]. Язучы үз хатларында укучы алдында хисләре, кичерешләре, бәя-хөкемнәре, әдәбиятка мөнәсәбәттә көтелмәгән борылышлар ясарга сәләтле иҗат кешесе буларак та ачылырга мөмкин.

Ул укучыны да әңгәмәдәш, фикердәш итеп карарга тели. Хатларда еш кына иҗат лабораториясе ачылып китәргә, булачак әсәрнең сюжет элементлары да күренеп калырга мөмкин. Алар авторның эстетик карашлары, холыкфигыльләре, яшәү рәвеше чагылу ягыннан да кыйммәтле. Кыскасы, язучыны аңлауда хат – киң мөмкинлекләр бирә торган жанр.

Шуңа күрәдер шагыйрьләр һәм әдипләр кайвакытта әдәби әсәрләрен дә хат өслүбендә язуга өстенлек бирәләр. Моның үрнәкләре төрле әдәбиятларда элек-электән үк була килгән. Антик чорда аларны «ярымдиалог», «биредә булмаучының мондагылар белән сөйләшүе» (Артемон) дип карау да булган. Цицерон, Сенеко, Плиний, Гораций хатлары, мәсәлән, хәзергә кадәр сакланган. Урта гасырлар Аурупа әдәбиятларына да хат чит-ят булмаган. Иеронимның, Павлин Ноланскийның шигъри хатлары билгеле. XVIII гасыр урталарында монда инде зуррак жанр – эпистоляр роман күренә башлый (Ричардсонның «Памела», Ж.Ж.Руссоның «Юлия, яки Яңа Элоиза», И.В.Гетеның «Яшь Вертерның газаплары»). Рус әдәбиятында да шушы жанрда «Эрнест һәм Доравра хатлары» (Ф.Эмин), «Роза», «Язмыш уены» (Н.Эмин) дигән әсәрләр иҗат ителә. Аларга М.Ломоносовның «Письмо о пользе стекла» әсәре өстәлә. XX гасырда без моның мисалла-

рын В.Маяковскийда күрәбез («Письмо к любимой Молчанова, брошенной им», «Письмо товарищу Кострову из Парижа о сущности любви»).

Төрки, шул исәптән татар әдәбиятында да хатлар өслүбендә әсәрләр язу традициясе шулай ук урта гасырлардан ук килә. Харәзминең «Мәхәббәтнамә» («Мәхәббәт хатлары») (1354), С.Әхмәтнең аның үрнәгендә язылган «Тәгашшыкнамә» («Гыйшык хатлары») (1435-1436) әсәрләре шуның мисаллары. XIX гасыр авторы Г.Кандалый иҗатында исә хат рәвешендә язуның бик матур үрнәкләрен күрәбез. Урта гасыр төрки-татар язма истәлекләрендә элгәрләребез җырлаган сөю хисләре аның әлеге поэма-хатларында җир кешеләренең табигый кичерешләренә тагын да якыная төшә. «Сәхипҗамал», «Фәрхи» кебек әсәрләре ике гасырдан соң да укучыларны нәкъ шул яклары белән җәлеп итәләр.

XX гасыр башында эпик төрнең кече жанры буларак үсеш кичергән хат иҗтимагый-милли мәсьәләләр, татар зыялыларының милләткә хезмәт итү, яшәүнең фәлсәфи һәм әхлакый нигезен эзләү юлындагы уйланулары, гамьнәре белән сугарыла. Аңа публицистик төсмер килеп кушыла. Мәсәлән, Ш.Әхмәдиевнең «Хат һәм җаваплар» (1912) әсәре [8: 212-1-212]. Бу чорда аның үрнәкләрен прозада һәм лирикада да күрергә мөмкин. Аерым алганда, М.Гафури тарафыннан романтик, хисси-эмоциональ эчтәлекле, матур «Мәхәббәт хатлары» (1912) әсәре языла.

XX гасырның беренче яртысында сәнгатьчә эшләнеш җәһәтеннән шактый камил булган «Киләчәккә хатлар» (Һ.Такташ), «Тапшырылмаган хатлар» (Г.Кутуй), «Пионерка Гөлчәчәккә хат» (1942) кебек поэма һәм повесть жанрына караган әсәрләр татар сүз сәнгате үсешендә вакыйга буларак кабул ителделәр. Аларның бүгенге укучы өчен дә әһәмиятләре кимемәгән. Һ.Такташ поэмасы егерменче-утызынчы еллардан гыйбрәтле шигъри репортаж булуы белән әһәмиятен җуймый. Г.Кутуй әсәре яңа чор татар хатын-кызының рух ныклыгына дан җырлауга өлеш кертсә, Ф.Кәримнең Гөлчәчәге азатлык өчен көрәшүче солдат белән тылдагы самими кыз баланың ватанга мәхәббәттә бердәй хисләренең тантанасын чагылдыра. А.Гыйләҗевнең «Кызлар язган хатлар» повесте (1970-1971) илебездәге төрле милләт яшьләренең яктыга, бәхеткә, камиллеккә омтылган күңелләренең канатлы уй-хисләрен чагылдырулары, романтик күңел дөньяларын ихлас ачып сөйләшүләре белән укучыларны мавыктырдылар, тормышка яңа аяк басучы яшьләргә табигый рәвештә яшәү үрнәге дәресләрен бирделәр. Бу әсәр хат өслүбендә язуның укучы белән әдипнең үзара ышанычлы фикердәш була алуының көчен күрсәтү ягыннан да әһәмиятле иде. Хәер, теге яки бу әсәрнең, язманың халкыбызның аерым вәкилләренә генә түгел, бәлки тулаем халыклар тормышына ясаган йогынтысына мисаллар тарихыбызда да бар. XVIII гасыр каһарманы Габдулла Баһадиршаһның аеруча хәлиткеч көннәрдә халыкка мөрәҗәгать итеп язган хаты бу очракта иң беренче булып хәтергә төшә. Милләттәшләренең омтылышларын тормышка ашыру вакыты җиткәнен игълан иткән бу өндәмә тарихыбызга «Батырша хаты» исеме белән кереп калды.

Язучыларыбызның ил язмышы хәл ителгән көннәрдә әйтәсе сүзләрен халыкка җиткергәндә хат өслүбенә мөрәҗәгать итүләре болар белән генә чикләнми. М.Әмир «Тормыш җыры» әсәрендә сугышчы Басыйрның тылдагы сөекле хатыны Фатыймага җыр ярдәмендә хат җибәрүен сурәтли. / «Җырга салып хат җибәрәм, / Фатыймам, / Җыр сөюче дусларым артыннан» / дигән сүзләр бу вакытларда фронттагылардан өзелеп хат көтүчеләрнең барысы өчен дә үтә тансык, кадерле иде. М.Җәлилнең «Җырларым», «Кичер, илем!» кебек шигырьләре дә туган халкына мөрәҗәгать итеп язылган хат дип исәпләнелә ала.

Х.Туфан да әдәби әсәрләрендә хат рәвешенә яратып мөрәҗәгать итте. Каләмдәш дусты Һ.Такташ вафаты уңае белән иҗат иткән «Ә үткәнгә хатлар бармыйлар» дигән циклы татар шигъриятенең энҗесе булдылар. Аның «Лирик хатлар»ы да алтмышынчы еллардагы иҗатында бер матур сәхифә иде. Шагыйрьнең Себердә тоткынлыкта язылган «Овидий Назон» дигән шигыре бар. Х.Туфан иҗатын тәфсилләп өйрәнгән М.Гайнетдин әйткәнчә, Х.Туфанның «Овидий кебек, әдәбиятка үз «Сагышлы элегияләрен» язып, әдәбиятны баету дәртенә килгәнен күреп була. Сталин режимы О.Август принципаты гына түгел шул. Себердән шигъри хатлар юллый алмасыннар өчен, ул адресатларның да кешелек сыйфатын юкка чыгарган. Аларга хат язу да, хат алу да мөмкин түгел» [9: 287].

Шулай итеп, матур әдәбиятта хат өслүбе дигәндә, без бу күренешнең ике төре турында сүз алып бара алабыз: чын мәгънәсендәге хатлар һәм эпистоляр стильдә иҗат ителгән

әсәрләр. Әгәр беренчесе күпчелек язучыларга хас булса (хат язышмыйча яшәгән каләм әһелен күз алдына китерү кыен), икенче төре аерым язучылар иҗатына гына карый. Әсәр язучының мондый алымны сайлавына башка әдәбиятлардагы шундый үрнәкләр дә тәэсир итә. Г.Кутуйның искә алынган «Тапшырылмаган хатлар»ы, мәсәлән, алман язучысы С.Цвейгның «Письмо незнакомки» әсәре үрнәгендә эпистоляр стильдә иҗат ителгәне мәгълүм.

Әдәбиятта иҗатның бу ике төрендә дә тирән эз калдырган авторлар да очрый. Без бу очракта шуларның берсе – татар шигърияте класссигы Хәсән Туфан иҗатына шушы ноктадан күз салуны максат иттек. Каләмдәшләре белән хат алышу сәхифәләрен күздән кичергәндә, Х.Туфан хатларының биографик фактларга бай булуына игътибар ителә. Шуның өстенә, аларны әдәби таләпләр ягыннан карау кирәклеге дә күренеп тора. Г.О.Винокур бик тә хаклы әйткәнчә, әнә А.С.Пушкин да үзенең хатларын әдәби әсәр таләбен куеп язган. «Ул аларда, һичшиксез, үзенчәлекле әдәби бурычны күрә» [10: 179]. Шул ук сүзләрне Х.Туфанга карата да әйтергә кирәк.

Шагыйрьнең хатлары иҗатының бик мөһим өлеше дип бәяләнергә хаклы. Без бу очракта аның Г.Минскийга һәм С.Кудашка язган хатларын тәфтишләү белән генә чикләнәбез. Әмма аларны әдәбиятыбыз тарихының берничә дистә еллык өлешенә күп яктан ачыклык кертүләре белән әһәмиятле дип саныйбыз. Гәрчә ул хатлар авторның шәхси уй-кичерешләрен җиткерүгә исәп тотылып язылган булсалар да, Х.Туфан кебек иҗат гаме белән яшәгән кешенең уйлану чикләре зур дәверне генә түгел, киң даирәне дә иңли. Хатлар, Р.Мостафин әйткәнчә, «Х.Туфанның кичерешләрен, аның дөньяга карашын, уй-фикерләрен күз алдына китерергә мөмкинлек бирә» [11: 177]. Сүз Х.Туфанның 1956 елның 18 июнендә Новосибирск өлкәсенең Устарка районындагы Покровка авылыннан Казанга – каләмдәше Габдрахман Минскийга язган хаты турында бара. Бу Х.Туфанның уналты ел тоткынлыкта булган чорда иҗатташ иптәшләренә язган беренче хаты. Бу инде, дөресен әйткәндә, рәсми рәвештә гаепсез дип табылып, ирекле дип игълан ителгәч, уйларының, шулай киң вә эзлекле булып, беренче тапкыр кәгазьгә күчүе. Әлеге фикерләүнең гадәти генә затныкы түгел, бәлки шагыйрьнеке икәнлеге хатның беренче юлларыннан ук күренә. «Йөрәк катнаша торган берәр хатны язарга утырдым исә, йөрәк катнашмаганнан яза да алмыйм, – әллә кайдан шунда, көтмәгәндә, уйламаганда (миңа шулай тоела), тота да берәр туасы шигырьнең аккорды яңгырый. Хат язылачасы кәгазьгә шуны теркәргә керешәм, күп вакытта ул, аккорд хәлендә генә калмыйча, үзенең янына бүтән кисәкләрен җыя, бөтен хәлгә килә. Менә сиңа хат язарга «утырган идем, тагын шундый хәлгә очрадым». Моннан күренгәнчә, Х.Туфан өчен хат язу да, нәкъ шигырь иҗат иткәндәге кебек, «йөрәк катнашмаса», барып чыкмый.

Билгеле булганча, йөрәк килеп катнашса, ул инде хисләр дулкынын кузгалта. Мондый халәт, әлбәттә инде, язучының беренче карашка гади хат булырга тиешле язмасын да нииндидер дәрәҗәдә әдәби әсәргә якынайта. «Һәр көнне хыялда Казан урамнарында йөреп кайтам. Мин анда уналты елдан бирле булганым юк. Менә шул озын чордан соң аның эченә керәм! Анда миңа танышлар калган иде. О, алар ничек зурайган, үскәннәр инде. Менә бу төштә проза туйралары, проза элмәләре, карамалары һәм юкәләре үсә иде. Туйралар инде имәндер, алар инде үскәндер. Ә бу төштә шигырь каеннарыусаклары, алмалары, сәрвиләре, сиреньнәре һәи шомыртлары калган иде. Алар инде ничек күкрәп чәчәк аткандыр. Ә бу якта тәнкыйть, сатира-юмор миләшләре, баланнары һәм өрәңгеләре дә тамыр җәйгән иде. Алар инде ничек ныгыгандыр» [11: 178].

Күренә ки, хатларны уку әдәби әсәрнең нәкъ үзе кебек кабул ителә. Нинди оста итеп тотып алынган охшату-чагыштырулар, параллельләр. Прозаны туйра, элмә, карама, юкәгә, ә шигъриятне каен-усак, алмагачлар, сәрвиләр, сиреньнәр һәм шомыртларга тиңләүне табигый кабул иткән кебек, тәнкыйть, сатира-юморны әче миләш, балан, каты тәнле өрәңгеләр белән тәңгәл куюны да әдәбиятның эчке хасиятенең һәм табигатенең күптөрле булуын аеруча нечкәләп белгән кеше генә эшли ала. Шул ук вакытта проза, шигърият һәм тәнкыйтьнең барысын да бертөрле итеп кенә карап булмый. Ничә автор булса, шулкадәр төрлелек булырга тиеш дип карау бу. Әлеге өзектән шагыйрьнең сүз сәнгатендәге әнә шундый эчке тирбәлешләрне сизгер тоемлавы күренә.

Х.Туфан үзенә язылган хатларга да иҗатчы буларак каравын белдерә. «Кадерле хатларны укуда мин уйланылмаганча эш итәм, хатны уку бәхетен озынайту өчен, беренче ноктагача укыйм да, торып китеп йөренәм, уйланам. Алдагы (әле укылмаган) җөмләнең эчтәлеге турында уйланам. Шул рәвешчә, хат гүяки искит-

кеч бер мавыктыргыч әсәргә, сюжетлы әсәргә әверелә» [11: 184]. Үзенә килгән хатны әдәби әсәр сюжеты итеп зурайтып, тулыландырып күрү сәләтенә ия Х.Туфанның үзе язганда ни рәвешле эш итүен күз алдына китерү кыен түгел. Ул инде иҗатчы йөрәге аша саркып чыккан хат рәвешен алачак. Башкача мөмкин дә түгел. Димәк, әлеге хатлар образлылык, эмоциональлек белән сугарылган текст булачак. Г.Минскийга язган хат турында сүз барганда, шуны әйтергә туры килә: бу шактый озын – дистә биттән артык текст әдәбияттан уналты елга читләштерелгән талант иясенең, бары тик үзен шигъри мохиттә генә бәхетле тойган шәхеснең үзе югында татар әдәбиятында барлыкка килгән, әлегә үзенә мәгълүм булган күренешләргә зур таләпләр югарылыгыннан торып бәя бирүнең бер үрнәге. Татар әдәбияты мондый гаять тыгыз гомумиләштерелүләр белән хат рәвешендә язылган билгеле бер чор эстетикасына иңләп бәя бирелүне бүтән белми.

Хаттан шул да аңлашыла: үзе аклангач, автор инде илдә сүзне иркенләп әйтерлек шартлар тудырылган дип фаразлый (чөнки әле иректә яшәп караганы юк). Юкса, шәхескә табыну чорында репресссиягә дучар ителгән Галим Г.Мөхәмитшин турында «разве ул халык алмазының үз иле алдында гаепле булуы мөмкин?» дигән җөмләне язарга җөрьәт итмәс иде. Биредә аның Г.Мөхәмитшин белән булган фаҗигане белмәве дә күренеп кала.

Әйе, әлеге хат – ике дус арасындагы самими мөнәсәбәтне генә түгел, бәлки аяк-кулларыннан тоткынлык богаулары төшкәч, шуның белән алда бөтенесе яхшы булырга тиеш дип өметләнгән Х.Туфанның дөньяга шагыйрьләрчә ихлас караганлыгын да күрсәтә торган этрафлы әдәби документ. Шуннан соң сигез ел үткәч (1964, март), Уфада яшәүче күренекле шагыйрь Сәйфи Кудашка язган хатында да шушы хасиятләрне күрәбез [12: 8-9]. Аларда шулай ук аерым кеше тормышында булган очраклар гына түгел, әдәбият, ил мохитенә бәйле хәлләр, шулардан туган кичерешләр тәэсирле, үтемле һәм образлы чагылыш тапкан.

Хатлар, чыннан да, сәнгать әсәре булуга якынаялар. Әйтик, беренче абзацы ук һәм стиле, һәм анда бәян ителгән фикерләр, хискичерешләр тыгызлыгы ягыннан да чәчмә әсәрнең башлап өлешен хәтерләтә. «Кабатланмас туганым, Сәйфи! Ах, күп тә соң сиңа әйтәсе, сөйлисе килгән уйлар, сәламнәр. Сөенәм дә менә, бераз көенәм дә. Сөенәм: дөньяда син бар, иң якын иткән кадерле туганым. Үткәнебез, яшьлегебез, киләчәгебез белән дә иң якын туганым булган кешем – син бар. Көенәм: /Өйне шигырь белән тутырып/ Бер сайрашыр идек утырып,/ диеп сагынышып яшибез үзебез. Ә күрешүләр, очрашулар нинди сирәк, сайрашып, серләшеп утыру сәгатьләре нинди кыска. Безнең күрешү кичәләре таңнарга тоташтырган сөйләшүләр, еллар буена йөрәккә тупланган өметләрне уртаклашырга дигән темаларның прологлары гына булып тоела, Сәйфи, прологлары гына. Без баркайчан да сайрашасы дигән өметләребезнең эпилогына барып җитмәбездер: безнең туганлык ил эшендә бергә януның эчтәлеге торган саен киңәя, тулылана, зурая бара. Тормыш аңа сәхифәләр – яңа битләр өстәп баета да баета гына. Син үзең дә сизмисеңдер, Сәйфи, ә миңа ачык күренә: иҗади канатың ныгый да ныгый, рухи байлыгың балкый да балкый гына. Синең шулай яктырып, балкып яшәвеңә сокланам да дулкынланам. Димәк, минем учакка да нур өстисең, яна-яна яшәргә илһамландырасың. Мин бары бер нәрсәгә, Сәйфи, кулыңнан каләм төшмәгәненә, авыруларга бирешмәвеңә ышанам: синең рух, бер яктан, давылларга чыныккан ветеран, икенче яктан һаман алгы сафта барган азамат» [13: 80].

Күрүебезчә, шагыйрьнең дустына булган ихтирам, сагыну хисләре шигырьне хәтерләтә. Образлылык чараларының төрле һәм мул кулланылуы текстның тәэсир көчен куәтләндерә. «Сәйфи! Кабатланмас туганым, Сәйфи!», «ныгый да ныгый», «балкый да балкый», «баета да баета», «яна-яна яшәргә» (кабатлаулар); «торган саен киңәя, тулылана, зурая бара», «яктырып, балкып яшәвеңә сокланам һәм дулкынланам» (градация); «таңнарга тоташтырган сөйләшүләр», «еллар буена йөрәккә тупланган өметләр», «ил эшенә бергә януның эчтәлеге», «яктырып, балкып яшәвеңә» (эпитетлар); «сөенәм дә, бераз көенәм дә», «син үзең сизмисеңдер, ә миңа ачык күренә» (антитезалар); «синең рух, бер яктан, давылларга чыныккан ветеран, икенче яктан, һаман алгы сафта барган азамат» (метафоралар); «Сөенәм – дөньяда син бар, иң якын иткән кадерле туганым. Үткәнебез, яшьлегебез, киләчәгебез белән дә иң якын булган кешем – син бар» (инверсияләр). Гадәти хатлар болай язылмый, аларда хис-тойгылар образлылык аша бирелми. Авторның ярты гасыр элек С.Кудаш белән «Галия» мәдрәсәсендә укыган вакытларында ук дуслашкан булуын искә төшерсәк, алар арасындагы җылы

мөнәсәбәтләрнең тирәнлеге тагын да ачыла төшә.

«Бу рухның тормышка, яшәүгә, халыкка мәхәббәте чиксез. Һичбер авыруга ишек ачмаячак. Тегендә, «җәһәннәмдә» тормыш миңа үзенең бер серен әйтте: Һәлакәт ул кешенең, адәм баласының өмете сүрелгәнен, яшәүгә ышанычы беткәнен сагалый. Өметең сүрелдеме, димәк, беттең». Шулай икәнен күрдем мин аның, тормышның. Ул безнең җаннарны аралый-аралый эндәште, боексак: «ярамый, ярамый: өмет беткәнне һәлакәт сагалый!». Яшәүгә мәхәббәт сүрелсә әгәр дә, тормас идек без кырыкка кадәр дә. Какса да ничә кат йөрәкне һәлакәт, ачмады ишекне аңарга мәхәббәт. Син дә үзеңнең бөтен гомерең белән, олы гомерең белән «ишекне» ачмауның, бирешмәүнең җанлы мисалы бит». Бу өзектә дә без сурәтләү чараларының бай мөмкинлекләре файдаланылуына тап булабыз. Алар ярдәмендә автор ике шәхеснең дә холык-фигылен күңелең белән тоярлык итеп күз алдына китерүгә ирешкән. Алдарак күрсәтелгән сурәтләү чараларына яңалары, аерым алганда, җанландыру өстәлгән: «Тормыш миңа үзенең бер серен әйтте», «Һәлакәт ул кешенең, адәм баласының өмете сүрелгәнен, яшәүгә ышанычы беткәнен сагалый», «Ул безнең җаннарны аралый-аралый эндәште», «Какса да ничә кат йөрәкне һәлакәт, ачмады ишекне аңарга мәхәббәт». Кайбер юлларның рифмалашып килүе дә хатны әдәби әсәргә якынайта.

Шагыйрь кемнедер гаепләп рәнҗеми, зарланмый. Күргәннәрен язуның максаты исә әлеге вакыйгалардан үзе өчен нинди нәтиҗә ясавы, көчле рухлы булып кала алуын әйтәсе килгәннән. Әлеге сүзләрне әйтүенең максаты – дустының да күңелен үзенә ышаныч белән ныгытырга теләү.

Хат 1964 елда язылган дидек. Бу – Х.Туфанның, кайтканына байтак вакыт үтсә дә, һаман әдәбиятта үз урыны алырга омтылу көннәре. Матбугатта сирәгрәк күрсәтергә тырышулары аның күңелен телгәли. Беренче китабы да шушы 1964 елда гына чыга ала. Хат әнә шул борчулы вакытта язылган. Хат эчендә «Бар ул, бар» шигыренең дә урын алуы шуны күрсәтә. Аның кебек «тегеннән» кайткан кешеләргә шикләнеп каручы берәүне шагыйрь чирканыч итеп сурәтли :

Әйтеп куйды ымлап-пышлап кына:
Болар бар да узкий патриот!
То-есть монда
Киң карашлы кеше
Почти юк.
Пантюркистлар болар…
Нәкъ Такташ кук,
Беспартийный болар һәммәсе:
Шикле, то-есть, телче кешеләр болар,
Безгә болар ишме!? янәсе.

Туфанны талантларга юл бирмәү, аяк чалу күренешләре тынгысызландыра, үзләреннән соң әдәбиятка килүчеләрнең сыйфаты борчый. «Без иҗтимагый киң колачлылар, без тыныч кына, мыштым гына, битараф кына обывательчә яши белмибез. Бездә, Аллага шөкер, андый «сәләт» юк. Ләкин, Сәйфи, уйлыйсың да, йөрәк жуу итеп куя. Ах, аз ла яна белүчеләр, ах, сай җанлылар да безне алмаштырачак яшьләр». «Язмыйча, дәшмичә калырга мөмкин түгел, Сәйфи, мөмкин түгел». Авторның болай кабатлап әйтүе аның нинди эмоциональ халәттә булганлыгын ачык күрсәтә.

Шагыйрь кешенең җәмгыятьтәге урыны турында гына түгел, аның табигать белән гармониясе турында да уйлана. «Тагын яз килде, Сәйфи, тагын килде. Табигатькә якынрак йөрергә кирәктер безгә, аңардан гыйбрәт алырга кирәктер, салкын канлы булырга, борчылмаска өйрәтә бугай ул безне». Болар аның табигать һәм кеше мөнәсәбәте мәсьәләсе күтәрелгән әсәрләренең сыгымтасы буларак кабул ителә.

Күргәнебезчә, документаль чыганак буларак, язучы хатларының әһәмияте аның күп сыйдырышлы күңел дөньясын аңлауда, иҗатының эчке хасиятләрен төшенүдә, образлылыкка ирешү чараларының байлыгын күз алдына китерүдә ачкыч булып хезмәт итүләрендә күренә. Х.Туфан кебек бөек шагыйрьләрнең хатлары турында сүз барганда, бу бигрәк тә шулай.

**Әдәбият**


1. *Гинзбург Л.Я.* О психологической прозе / Подгот. текста С.В.Путилов. М.: INTRADA, 1999. 415 с
2. *Антоненко С.В.* Структура писем А.С. Пушкина: лингвостилистика текста. М.: Знание, 2000. 154 с
3. *Гыйлаҗев Т.Ш.* Рецензияләрдән тәгъзияләргә: ХХ йөз башы татар әдәби тәнкыйте. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. 254 б.
4. *Харрасова Р.Ф.* Әдәби тәнкыйть теориясе. Казан: Казан дәүләт ун-ты, 2007. 32 б.
5. *Закирзянов А.М.* Основные направления развития современного татарского литературоведения (кон. ХХ – нач XXI в.). Казань: Ихлас, 2011. 320 с.
6. *Тукай Г.* Әсәрләр. 5 томда. 5 том / Истәлекләр, кулъязмалар,хатлар. Мәсәлләр һәм балалар өчен

язылган хикәяләр (1902-1913). Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 368 б.
7. *Гыйлаҗев Т.Ш.* Тукай – тәнкыйтьче // Мәгариф, 2011, №4 (902). 9-13 б.
8. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. 231 б.
9. *Гайнетдин М.* Хәсән Туфан // Хакыйкать юлыннан. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 267-305 б.
10. *Винокур Г.О.* О языке художественной литературы. М.: Высшая школа, 1991.477 с.
11. *Мустафин Р.* Хәсән Туфан хаты // Казан утлары. 1988. № 2. 177-185 б.
12. *Гайнетдин М.* Хатлар йөри ике арада // Ватаным Татарстан. 1993. 20 август. 8-9 б.
13. *Даутов Р.Н.* Балачак әдипләре: Биобиблиографик белешмәлек. Икенче китап. Казан: Мәгариф, 2004. 284 б.

# ПИСЬМА ХАСАНА ТУФАНА В СВЕТЕ ЕГО ЭСТЕТИЧЕСКИХ ВЗГЛЯДОВ

**Илюса Джавдатовна Исмагилова,**
**Раиф Кадимович Амиров,**
Башкирский государственный педагогический университет им.М.Акмуллы,
Россия, 450000, г.Уфа, ул.Октябрьской революции, 3а,
ismagilova.ilyusa@mail.ru

**Фоат Галимуллович Галимуллин,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г.Казань, ул.Кремлевская, 18
aifiya_gali@rambler.ru

В статье идет речь о значении документальных материалов, мемуаров и писем как незаменимых источников, раскрывающих особенности развития литературного процесса в разные эпохи и позволяющих изучить внутренний мир поэта, его связи с внешним миром и то, как этот мир преломляется в его творчестве. Определяется степень изученности данных видов источников и предъявляемые к ним требования. Основная часть статьи посвящена изучению специфики писем Х.Туфана, адресованных его духовным соратникам Г.Минскому и С.Кудашу: рассматривается отношение поэта к проблемам, которые беспокоили его в то время, выявляются свойственные письмам художественные особенности.

**Ключевые слова:** мемуарная литература, эпистолярный стиль, письма, адресат, искусство документализма.